МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

**от “ 29 ” февраля 2016** **№ 77**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле үткәргәндә җәлеп ителгән экспертларны аттестацияләү комиссиясе турында нигезләмәсен раслау хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелек) үткәрергә вәкаләтле органнар, муниципаль контроль органнары тарафыннан контроль буенча чаралар үткәрергә җәлеп ителгән экспертларны аттестацияләү турында» 2014 елның 10 июлендәге 636 номерлы карарын үтәү йөзеннән **боерык бирәм**:

1. Кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле үткәргәндә җәлеп ителгән экспертларны аттестацияләү комиссиясе турында нигезләмәсен;

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле үткәргәндә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан җәлеп ителгән экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләрен.

2. Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты булеге мөдире Н.Н. Доброхотовка әлеге боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары А.В. Егоровка йөкләргә.

Министр Л.Р. Сафин

Татарстан Республикасы
транспорт һәм юл
хуҗалыгы министрлыгының
2016 елның 29 февралендәге
77 номерлы боерыгы белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ҖИҢЕЛ ТАКСИДА ПАССАЖИРЛАР ЙӨРТҮ ҺӘМ БАГАЖ ТАШУ ӨЛКӘСЕНДӘ РЕГИОНАЛЬ ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕ ҮТКӘРГӘНДӘ ҖӘЛЕП ИТЕЛГӘН ЭКСПЕРТЛАРНЫ АТТЕСТАЦИЯЛӘҮ КОМИССИЯСЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле үткәргәндә җәлеп ителгән экспертларны аттестацияләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле үткәргәндә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан җәлеп ителгән экспертларны аттестацияләүне тәэмин итү максаты белән төзелә (алга таба – экспертлар).

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль закончылыкка, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы закончылыгына таяна.

1.3. Объективлык, ачыклык, бәйсезлек Комиссия эшчәнлегенең төп принциплары булып тора.

1.4. Комиссия әгъзалары үз эшчәнлекләрен түләүсез нигездә алып баралар.

## 2. Комиссиянең вәкаләтләре

2.1. Комиссия түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

эксперт статусына дәгъва кылучының квалификациясен тикшерү максатында квалификация имтиханын үткәрү;

квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча дәгъва кылучының аттестация критерийларына туры килүе яисә туры килмәве турында карар кабул итү.

2.2. Комиссия әгъзалары Комиссия составына һәм аның эш тәртибенә үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрен раслау өчен Комиссия рәисенә кертергә хокуклы.

## 3. Комиссия составы һәм эш тәртибе

3.1. Комиссия Министрлык тарафыннан дүрт кешелек итеп төзелә.

3.2. Комиссиянең персональ составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына Комиссия рәисе, Комиссия секретаре, ике Комиссия әгъзасы керә.

3.3. Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, аның утырышларында рәислек итә, Комиссия эшен оештыра, хәлиткеч тавышка ия булып, Комиссиядә тавыш бирүдә катнаша, Комиссия карарлары беркетмәләрен имзалый.

3.4. Комиссия секретаре Комиссиянең рәсми документларын алып бара, Комиссия утырышында көн тәртибе белән таныштыра, Комиссия карарлары беркетмәләрен яза.

3.5. Комиссия эшенең төп формасы – утырышлар, анда квалификация имтиханнары уздырыла.

3.6. Комиссия аттестация турында гариза кергәннән соң 3 айдан да соңга калмый квалификация имтиханы үткәрә.

3.7. Комиссия карарлары ачык тавыш бирүгә, гади юл – утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының күпчелеге тавышына таянып кабул ителә. Утырышта Комиссия әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашкан очракта Комиссия үз компетенциясенә караган сорауларны хәл итәргә хокуклы. Тавышлар тигез булган очракта Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

3.8. Комиссия карары Комиссия секретаре тарафыннан алып барыла торган беркетмәгә теркәлә һәм Комиссия утырышында рәис тарафыннан утырыш уздырылган көнне имзалана.

## 4. Квалификация имтиханын үткәрү тәртибе

4.1. Квалификация имтиханын үткәрү көне Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында квалификация имтиханы үткәрелергә кадәр 10 эш көне алдан урнаштырыла.

4.2. Аттестация узу өчен, эксперт аттестациясен алу өчен дәгъва кылучы гражданин (алга таба - дәгъва кылучы) Министрлыкка әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегендә билгеләнгән критерийларга туры килүне раслый торган түбәндәге документларны тапшыра:

а) әлеге Нигезләмәнең Кушымтасындагы формага ярашлы рәвештә аттестация турында гариза;

б) паспорт күчермәсе;

в) хезмәт кенәгәсе яисә эш стажын раслый торган башка документ күчермәсе;

г) диплом күчермәсе;

д) өстәмә белгечлекләр алу, квалификацияне күтәрүне һәм белем алуны раслый торган башка булган барлык документларның күчермәләре.

4.3. Әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктында күрсәтелгән документларны Министрлыкка дәгъва кылучы шәхсән үзе тапшыра яисә почта элемтәсе аша иясенә тапшырылу турында белдерү кәгазе беркетелгән заказлы хат, яисә гади электрон имза куелган электрон документ шәкелендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша җибәрә.

4.4. Квалификация имтиханы әңгәмә-сөйләшү формасында уздырыла. Квалификация имтиханы барышында Комиссия әгъзалары квалификация имтиханын үтүгә кертелгән дәгъва кылучының Министрлык тарафыннан алдан ук тикшерелгән документлары белән танышалар.

4.5. Комиссия дәгъва кылучының автомобиль транспортында, шул исәптән җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә, транспорт чараларын йөртүчеләр белән эшләгәндә һәм бу транспорт чараларын эксплуатацияләгәндә тиешле чаралар үткәрү һәм кирәкле документацияне алып бару буенча законнар таләпләрен белү дәрәҗәсен билгели.

4.6. Квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча Комиссия дәгъва кылучының әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегендә каралган аттестация критерийларына туры килүе яки туры килмәве турында дәлилле карар кабул итә.

4.7. Квалификация имтиханы нәтиҗәләре Комиссия беркетмәсендә теркәлә. Беркетмә, әгәр квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча дәгъва кылучының аттестация критерийларына туры килүе турында карар кабул ителсә, дәгъва кылучыны аттестацияләү турында, әгәр квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча дәгъва кылучының аттестация критерийларына туры килмәве турында карар кабул ителсә яисә ул квалификация имтиханына килмәсә, дәгъва кылучыны аттестацияләүдән баш тарту турында Министрлык боерыгы чыгаруга нигез булып тора.

4.8. Дәгъва кылучыга әлеге Нигезләмәнең 4.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң 3 эш көне эчендә почта элемтәсе аша иясенә тапшырылу турында белдерү кәгазе беркетелгән заказлы хат яки гади электрон имзалы электрон документ шәкелендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша җибәрелә (иясенә тапшырыла).

4.9. Министрлыкның һәм аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата Россия Федерациясенең дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турындагы законнарына ярашлы рәвештә суд тәртибендә һәм шулай ук судка кадәрге тәртиптә дәгъва белдерергә була.

## 5. Экспертларны аттестацияләү критерийлары

5.1. Аттестацияләнгән эксперт булырга дәгъва кылучы зат җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу белән шөгыльләнүче яисә җиңел такси эшчәнлеге белән бәйле башка хезмәтләр күрсәтә торган (пассажирлар һәм багаж ташучыларга үтәү өчен заявкалар тапшыру, җиңел такси буларак кулланыла торган транспорт чараларын йөртүчеләрне рейска кадәр һәм рейстан соң медицина

тикшерүен үткәрү һәм мондый машиналарның техник торышын күзәтеп тору хезмәтләре күрсәтү) индивидуаль эшкуар, мондый предприятиене гамәлгә куючы, аның җитәкчесе яисә башка вазыйфаи заты булырга тиеш түгел. Аттестацияләнгән эксперт булырга теләгән затның мондый предприятиеләр белән шартнамәчел мөнәсәбәтләре булырга тиеш түгел.

5.2. Дәгъва кылучыдан түбәндәгеләр таләп ителә:

а) югары яисә урта һөнәри белем;

б) автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә тикшереп тору органнарында яисә юл хәрәкәте иминлеге органнарында кимендә биш ел эш стажы;

в) автомобиль транспортында, шул исәптән җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә, транспорт чараларын йөртүчеләр белән эшләгәндә һәм бу транспорт чараларын эксплуатацияләгәндә тиешле чаралар үткәрү һәм кирәкле документацияне алып бару буенча законнар таләпләрен белү;

г) автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә яисә юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә тикшереп тору буенча тәҗрибә һәм һөнәри күнекмәләр.

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле үткәргәндә җәлеп ителгән экспертларны аттестацияләү комиссиясе турында нигезләмәгә Кушымта

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына
____________________________
Адрес ____________________
Телефон номеры___________

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле үткәргәндә җәлеп ителгән экспертның аттестация турында
Гаризасы

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле үткәргәндә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан җәлеп ителгән эксперт аттестациясен узу өчен мине ___________________________________
____________________________________________________________________________
(дәгъва кылучының ФИО)

квалификация имтиханына кертүегезне сорыйм.

Үзем турында түбәндәгеләрне хәбәр итәм:
Регистрация урыны буенча адрес ___________________________________________
Шәхесне таныклый торган документ мәгълүматлары __________________________
_________________________________________________________________________
(сериясе, номеры, кайчан һәм кем биргән)
Телефон номеры ______________________________________________
Электрон почта адресы _________________________________________
ИНН ______________________________________________________

Тәкъдим ителгән белешмәләрнең актуальлеген һәм дөреслеген раслыйм ___________
(имза)

Персональ белешмәләрне тикшерүгә каршы түгел _______________

(имза)

Түбәндәге документлар кушымта итеп бирелә: ________________________________
(документлар исемлеге)

________________ ________________
(дата) (имза)

Татарстан Республикасы
транспорт һәм юл
хуҗалыгы министрлыгының
2016 елның 29 февралендәге
77 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле үткәргәндә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан җәлеп ителгән экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле үткәргәндә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан җәлеп ителгән экспертлар реестрын шәкелләштерү һәм алып бару тәртибен билгелиләр (алга таба – Реестр, Министрлык), шул исәптән Реестрга кертелә торган мәгълүматлар составын да.

1.2. Реестрны шәкелләштерү һәм алып баруны тәэмин итү Министрлыкның Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты булеге тарафыннан башкарыла.

1.3. Реестр Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырыла: http://mindortrans.tatarstan.ru/rus/taxsi.htm

## 2. Экспертлар Реестрын шәкелләштерү һәм алып бару тәртибе

2.1. Реестрны шәкелләштерү һәм алып бару Реестрга экспертлар турында мәгълүматларны кертүне, мәгълүматларны саклауны, системалаштыруны, актуальләштерүне үз эченә ала.

2.2. Министрлыкның экспертны аттестацияләү, яңадан аттестацияләү, аттестациянең гамәлдән туктатылуы турындагы карары Экспертлар турында мәгълүматларны Реестрга кертү өчен нигез булып тора.

2.3.Экспертлар турында мәгълүматлар Реестрга әлеге Кагыйдәләрнең 2.2 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң 3 эш көне эчендә кертелә.

## 3. Реестрга теркәлгән мәгълүмат

3.1. Реестрда түбәндәге мәгълүматлар бар:

а) язуның теркәлү саны;

б) эксперт турындагы мәгълүматларның Реестрга кертелү датасы;

в) экспертның фамилиясе, исеме, атасының исеме (әгәр булса);

г) экспертның яшәү урыны адресы;

д) шәхесне таныклый торган документ мәгълүматлары;

е) экспертның телефон номеры һәм электрон почта адресы (әгәр булса);

ж) экспертның салым түләүченең идентификацион номеры;

з) аттестация турындагы карарның номеры һәм аны кабул итү датасы;

и) яңадан аттестацияләү турындагы карарның номеры һәм аны кабул итү датасы;

к) эксперт аттестациясенең гамәлдән туктатылуы турында карарның номеры һәм аны кабул итү датасы;

л) экспертның квалификациясе турында мәгълүмат, шул исәптән квалификация күтәрү, яңадан һөнәри әзерлек үтү турындагы белешмә;

м) экспертның белеме һәм эш тәҗрибәсе турында мәгълүмат;

н) эксперт эшләгән яисә хезмәт күрсәтү максатыннан ул хезмәттәшлек иткән оешманың атамасы һәм урнашкан урыны.

3.2. Реестрга кертелгән мәгълүматлар танышу максатында дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик һәм физик затлар өчен ачык (Россия Федерациясе законнарына ярашлы рәвештә танышу чикле мәгълүматларга карамаганнарыннан тыш).

3.3. Реестрга кертелгән мәгълүматларның ачыклыгы әлеге мәгълүматларны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштыру юлы аша тәэмин ителә.